**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында карар**

«22» ноябрь 2024 ел № 11

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 22 ноябрендә узган халык җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2025 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 261 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 140 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 140 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 0 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Якушкино авыл җирлегенең Салдакай авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәүче, 1 гр инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарының тол хатыннары һәм көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан кала, 2025 елда һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат

муниципаль районының Якушкино авыл җирлеге Салдакай авылы мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Якушкино авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче: Х.Х.Хәмидуллин

Якушкино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Хәмидуллин